СОВЕТ
СРЕДНЕКУШКЕТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КӨШКӘТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ**
«26» апреля 2021 г.

**КАРАР**
№ 22

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлегенең Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә кермәгән территориясендә яшел утыртмаларны кисү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын үтәүнең көтелгән нәтиҗәләре һәм республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елга бурычлары буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең уртак коллегиясенең 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы Беркетмәсенең 24 пунктын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге Советының 2021 елның 12 мартында 20 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлегенең Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә кермәгән территориясендә яшел утыртмаларны кисү тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 3.18 пунктны өстәргә:

«3.18. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч барлыкка килгәндә рөхсәт бирелми.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Урта Көшкәт авыл җирлеге башлыгы: Перфилов Ю.М.